ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
БИШЕНЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ

# КАРАР

2026 ел,17 август № 60

## Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Дәүләт хакимиятенең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль канунына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2021 елның 9 августындагы 61 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә, 6 маддәнең 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Совет депутатына үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен эш бирүче тарафыннан эш урынын (вазыйфасын) саклап калып эшләүдән азат ителү, дәвамлылыгы Татарстан Республикасы Кануны нигезендә район Уставы белән билгеләнә торган һәм аена ике эш көненнән кимрәк һәм алты эш көненнән артыграк була алмаган чорга гарантияләнә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Апас муниципаль районы Башлыгы урынбасары Л.Т. Хәнтимировга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль
районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Совет Рәисе А.Г. Җиһаншин